# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«17» 03 2026ел Яр Чаллы ш. № 798

«Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләрендә укучы һәм тәрбияләнүче балаларына өстәмә ярдәм чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 3163 номерлы карарга үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләрендә укучы һәм тәрбияләнүче балаларына ярдәм итү максатында, «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге Федераль законның 8 статьясы, «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияне игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карарына, Тукай муниципаль районы уставының 29 пункты 6 статьясы, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 07 октябрендәге 26-6-10-В-13621 номерлы хаты, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2022 елның 9 ноябрендәге под-1903/22 номерлы боерыгы нигезендә, Тукай муниципаль районы Башлыгының 2022 елның 30 сентябрендәге 35 номерлы күрсәтмәсе нигезендә

## КАРАР БИРӘ:

1. «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләрендә укучы һәм тәрбияләнүче балаларына өстәмә ярдәм чаралары турында» Башкарма комитетның 2022 елның 20 октябрендәге 3163 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге редакциядә 6 пунктча өстәргә:

«6) әлеге чараларны электрон форматта күрсәтергә техник мөмкинлек булганда.»

2. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (https://tukay.tatarstan.ru) 3 эш көне дәвамында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы финанс бюджет палатасына мәгариф учреждениеләре эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә каралган акча средстволарын үз вакытында бүлеп бирүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов